КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 14 апрель

г.Казань

№ 285

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1100 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1100 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 9 март, 133 нче; 2016 ел, 8 май, 286 нчы; 2016 ел, 21 июнь, 419 нчы; 2016 ел, 4 октябрь, 715 нче; 2016 ел, 22 декабрь, 968 нче; 2017 ел, 6 июнь, 345 нче; 2017 ел, 21 ноябрь, 894 нче; 2017 ел, 30 декабрь, 1133 нче; 2019 ел, 16 февраль, 111 нче, 2019 ел, 05 сентябрь, 774 нче, 2019 ел, 17 октябрь, 923 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.3.2 пунктының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3.2. Социаль хезмәт күрсәтүләрне тиешле социаль хезмәт күрсәтү белән тәэмин итүчедән алуга ихтыяҗ аларны күрсәтү мөмкинлегеннән арткан очракта

социаль хезмәтләрне алучыларны картлар һәм инвалидлар өчен интернат-йортларга (пансионатларга), картлар һәм инвалидлар өчен махсус интернат-йортларга стационар социаль хезмәт күрсәтүгә кабул итү Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә социаль хезмәтләр белән тәэмин итүче формалаштыра торган чират нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

3.3.2 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.2. Социаль хезмәт күрсәтүләрне тиешле социаль хезмәт күрсәтү белән тәэмин итүчедән алуга ихтыяҗ аларны күрсәтү мөмкинлегеннән арткан очракта социаль хезмәтләрне алучыларны психоневрологик интернатларга стационар социаль хезмәт күрсәтүгә кабул итү Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә социаль хезмәтләр белән тәэмин итүче формалаштыра торган чират нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

4.3.1 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.3.1. Социаль хезмәт күрсәтүләрне тиешле социаль хезмәт күрсәтү белән тәэмин итүчедән алуга ихтыяҗ аларны күрсәтү мөмкинлегеннән арткан очракта социаль хезмәтләрне алучыларны акылга зәгыйфь балалар өчен интернат-йортларга, физик мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен интернат-йортларга стационар социаль хезмәт күрсәтүгә кабул итү Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә социаль хезмәтләр белән тәэмин итүче формалаштыра торган чират нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

5.1.1 пунктта «*****» астөшермәсендә «а» – «е» пунктчаларында» сүзләреннән соң «һәм «з» сүзләрен өстәргә;

5.3.1 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Социаль хезмәт күрсәтүләрне тиешле социаль хезмәт күрсәтү белән тәэмин итүчедән алуга ихтыяҗ аларны күрсәтү мөмкинлегеннән арткан очракта социаль хезмәтләрне алучыларны социаль хезмәт күрсәтүгә кабул итү Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә социаль хезмәтләр белән тәэмин итүче формалаштыра торган чират нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

5.3.2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучы һәр кешегә социаль хезмәт күрсәтүгә кабул иткәндә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча тернәкләндерү картасы төзелә. Социаль хезмәт күрсәтү тәмамланганнан соң, тернәкләндерү картасы социаль хезмәтләрдән файдаланучының шәхси делосына кушыла.»;

5.4.2 пунктның өченче абзацында «тормыш эшчәнлегенең төп категорияләрендә 2, 3 дәрәҗә чикләүләре булган инвалидны (инвалид баланы) реабилитацияләүнең яисә абилитацияләүнең индивидуаль программасында» сүзләрен төшереп калдырырга;

6.3.22 пунктның беренче абзацында «Россия Федерациясе Баш дәүләт санитар табибының 2003 елның 11 мартындагы 13 номерлы карары белән расланган «СанПиН 2.4.1201-03 «2.4. Балалар һәм яшүсмерләр гигиенасы. Социаль реабилитациягә мохтаҗ балигъ булмаганнар өчен махсуслаштырылган учреждениеләрне төзүгә, карап тотуга, җиһазлауга һәм эш режимына гигиеник таләпләр. Санитар-эпидемиологик кагыйдәләр һәм нормативлар» сүзләрен «Россия Федерациясе Баш дәүләт санитар табибының 2015 елның 9 февралендәге 8 номерлы карары белән расланган «СанПин 2.4.3259-15 «Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмаларның эш режимын булдыруга, карап тотуга һәм оештыруга карата санитар-эпидемиологик таләпләр» сүзләренә алмаштырырга»;

7.3.1 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Социаль хезмәт күрсәтүләрне тиешле социаль хезмәт күрсәтү белән тәэмин итүчедән алуга ихтыяҗ аларны күрсәтү мөмкинлегеннән арткан очракта социаль хезмәтләрне алучыларны социаль хезмәт күрсәтүгә кабул итү Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә социаль хезмәтләр белән тәэмин итүче формалаштыра торган чират нигезендә гамәлгә ашырыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин